**Исполнительный комитет**
**Большецильнинского сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Зур Чынлы авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

422461, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с.Большая Цильна,
ул.Советская, 13 тел.(84375)38-6-16,факс 38-6-35 Bcel.Drz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№2 2018 елның 13 феврале

Авыл җирлегенең 2018 елга терроризм
һәм экстремистлыкка каршы профилактик
чараларның планын раслау турында

«Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы федераль закон, «Терроризмга каршы көрәш турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында» 19.12.2012 № 1666 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, Зур Чынлы авыл җирлеге Уставы нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру кысаларында эшчәнлекнең төп юнәлешләрен билгеләү максатларында-терроризмны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу, шулай ук экстремизмны минимальләштерү һәм (яки) Зур Чынлы авыл җирлеге территориясендә терроризм һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен бетерү турында Зур Чынлы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлегендә 2018 елга терроризмны һәм экстремизмны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар планын расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карар халыкка рәсми рәвештә игълан ителгән көннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.Татарстан Республикасы

Зур Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Ф.С.Хәлиуллов

13.02.2018 елның №2
карарына кушымта.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Зур Чынлы авыл

җирлегендә 2018 елга терроризмны һәм экстремизмны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар планы

| № п/п | Чаралар исемлеге | Җаваплы башкаручылар | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| 1 | Торак фондның террорга каршы яклануын камилләштерү эшен оештырырга | Авыл җирлеге башлыгы | 2018 ел |
| 2 | Куркынычсызлыкны көчәйтүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру:<br>- торак йортлар һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарда;<br>- уку һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә,<br>сәламәтлек саклау учреждениеләре, даими яшәү урыннары һәм кешеләрнең озак тоткарлану урыннарында | Авыл җирлеге башлыгы, оешма җитәкчеләре (килешү буенча) | даими |
| 3 | Оешмаларның һәм аның янәшәсендәге территорияләрнең террорчылыкка каршы якланганлыгын һәм янгын куркынычсызлыгын комплекслы тикшерүне үткәрергә | Авыл җирлеге башлыгы, янгыннан саклану хезмәте башлыгы (килешү буенча), полициянең участок уполномоченные (килешү буенча) | Май 2018 ел |
| 4 | Авыл җирлеге территориясендә законсыз булган затларны билгеләү буенча, буш һәм арендага алына торган торак йортларны даими тикшерүне оештырырга | Авыл җирлеге башлыгы, полициянең участок уполномоченные | даими |
| 5 | Террорчылыкка каршы көрәш мәсьәләләре буенча уку, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре белән киңәшмәләр үткәрү | Авыл җирлеге башлыгы | август 2018 ел |
| 6 | Терроризмга һәм экстремизмга | Авыл җирлеге | 2018 ел, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | каршы тору буенча күрелә торган чаралар турында авыл җирлеге халкына даими мәгълүмат бирүне оештырырга | башлыгы | даими |
| 7 | Терроризм һәм экстремизмның асылын, аның башлангыч нәтиҗәләрен аңлату максатыннан мәгариф, мәдәният учреждениеләрендә пропаганда эшен оештырырга | оешма җитәкчеләре (килешү буенча) | 2018 ел |
| 8 | Авыл җирлеге территориясендә ташландык йортларның исемлеген ачыклау. Әлеге объектларда шикле затлар, предметлар һәм әйберләр булу (яшәү) фактлары турында хокук саклау органнарына вакытында хәбәр итәргә | Авыл җирлеге башлыгы | даими |
| 9 | Торак биналарны поднаемга тапшыручы затларны һәм гражданнарның торак урыннарында теркәлмичә яшәү фактларын ачыклау. Эчке эшләр министрлыгына вакытында хәбәр итү | Полициянең участок уполномоченные | даими |
| 10 | Чит ил эшче көчләреннән законсыз файдалану фактларына чик кую; федераль миграция хезмәтенең Урта Азия һәм Төньяк Кавказ регионнарыннан чыккан эшчеләр турында вакытында хәбәр итү | Авыл җирлеге башлыгы | даими |
| 11 | Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан кылынган миграция буенча хокук бозулар, террорчылык янавын һәм экстремистик күренешләрне кисәтү буенча профилактик эш алып барырга | Авыл җирлеге башлыгы | даими |
| 12 | Депутатларны хокук бозуларны кисәтү буенча чаралар үткәрүгә җәлеп итү | Авыл җирлеге башлыгы | 2018 ел |
| 13 | Массакүләм чаралар үткәргәндә оешмаларда гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре буенча профилактик | Авыл җирлеге башлыгы, оешма җитәкчеләре (килешү буенча) | квартал саен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эш оештыру. | участок уполномоченные | |
| 14 | Оешмаларның матди-техник базасын ныгыту, шул исәптән яктырту һәм коймалар, янгынга каршы инвентарь булу буенча чаралар күрергә. | оешма җитәкчеләре (килешү буенча) | 2018 ел |
| 15 | Йортларны карап чыгу вакытында, яшәү урыны буенча җыелышларда халык белән профилактик эш алып бару | Авыл җирлеге башлыгы | апрель-май |
| 16 | Терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча авыл китапханәсендә күрсәтмә материаллар әзерләргә | китапханәче(килешү буенча) | 2018 елның июненә кадәр |